ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

_______________          с. Верхний Услон          _______________

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
«Макыл урта гомуми белем бирү
мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми
белем бирү учреждениесенең исемен
үзгәртү һәм Уставны үзгәрешләр белән
раслау турында

Югары Ослан муниципаль районының Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе администрациясе һәм педагогик коллективының, Югары Ослан муниципаль районының «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә, аның хәтерен мәңгеләштерү, укучыларның һәм яшьләрнең рухи-әхлакый тәрбиясен камилләштерү максатыннан чыгып Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Исаев исемен бирү турындагы мөрәҗәгатен карап, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен Югары Ослан муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Исаев исемендәге Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе дип үзгәртергә.

2. Югары Ослан муниципаль районының «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Исаев исемендәге Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставына үзгәрешләр кертергә һәм аларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1). Пункт 1.1: Әлеге Устав «Советлар Союзы Герое Алексей Петрович Исаев исемендәге Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе эшчәнлеген алга таба «А.П. Исаев исемендәге Макыл урта мәктәбе» (алга таба - Учреждение) регламентлаштыра һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2013 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү максатларында эшләнгән.

2). Пункт 1.3: Учреждениенең тулы рәсми исеме:
рус телендә - муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Макуловская средняя общеобразовательная школа имени героя Советского Союза Алексея Петровича Исаева» Верхнеуслонского муниципального района Республики Татарстан;
татар телендә – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Советлар Союзы герое Алексей Петр улы Исаев исемендәге Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе.
Кыскартылган исем:
рус телендә - МБОУ «Макуловская СОШ им. А.П. Исаева»;
татар телендә – МБГБУ «А.П. Исаев исемендәге Макыл УГББМ»

3). Пункт 1.5: «А.П. Исаев исемендәге Макыл УГББМ» МБГБУ коммерциячел булмаган оешма булып тора.
Оештыру - хокукый форма - учреждение.
Муниципаль учреждение тибы - бюджет учреждениесе.
Белем бирү оешмасының төре - гомуми белем бирү оешмасы.

4). 1 бүлектән 1.6 пунктын төшереп калдырырга.

3. Уставка һәм «Советлар Союзы герое Алексей Петрович Исаев исемендәге Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең башка оештыру документларына кертелүче үзгәрешләрне дәүләт теркәве буенча мөрәҗәгать итүче вәкаләтләрен Югары Ослан муниципаль районының «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе директоры Панасик Николай Владимировичка бирергә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе В.С. Тимиряев

5 нөсхәдә
әзерләде һәм бастырды:
В.В. Касимов